**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№8200**
**08.09.2023**

«Автокаланың яшь эшмәкәре – 2023»
конкурсын әзерләү һәм үткәрү турында

Яшьләр мохитендә эшмәкәрлекне популярлаштыру, актив яшь кешеләрне ачыклау һәм бүләкләү максатында һәм Башкарма комитетның 2019 елның 30 октябрендәге 5586 номерлы карары белән расланган «2020-2023 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенә Яр Чаллы шәһәрендә «Автокаланың яшь эшмәкәре – 2023» шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурска әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурска әзерлек һәм аны үткәрү чыгымнарын финанслауны 2023 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 112 800,00 (йөз унике мең сигез йөз сум 00 тиен) күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 8 сентябрендәге
8200 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Ел эшмәкәре»
шәһәр конкурсы турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә Яр Чаллы шәһәрендә «Автокаланың яшь эшмәкәре – 2023» шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели. Конкурсны оештыручы булып Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе тора.

2. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) конкурсны үткәрү тәртибен аңлата;

2) конкурста катнашучыларның заявкаларын кабул итә;

3) тәкъдим ителгән проектлар нигезендә конкурсның жюри составын формалаштыра;

4) конкурста катнашучыларның исемлеген раслый;

5) конкурс финалын үткәрү көнен билгели.

2 бүлек. Конкурсның максаты һәм бурычлары

3. Конкурсның максаты булып яшьләр мохитендә, нәтиҗәле тормыш стратегиясе буларак, эшмәкәрлекне популярлаштыру тора.

3. Конкурсның бурычлары:

1) илнең икътисадый-социаль прогресс факторы буларак, яшьләр эшмәкәрлегенең позитив имиджын формалаштыру һәм популярлаштыру;

2) эшмәкәрлек эшчәнлеген алып баручы актив һәм сәләтле яшьләрне ачыклау һәм бүләкләү;

3) яшьләр мохитендә охшарга тырышу өчен үрнәкләр булдыру;

4) яшьләр эшмәкәрлеген үстерү өчен шартлар булдыру, яшь эшмәкәрләр базасын формалаштыру.

3 бүлек. Конкурста катнашучылар

5. Конкурста Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче 18 яшьтән 35 яшькә кадәрге Россия Федерациясе гражданнары катнаша ала. Конкурста бер компаниянең шәхси эшмәкәрләре, гамәлгә куюда катнашучылары яки җитәкчелек вәкилләре булган берничә физик зат катнаша ала. Конкурста бергә катнаша һәм үзләренең уртак бизнесын тәкъдим итә торган мондый затлар төркеме бер катнашучы буларак карала.

6. Конкурста катнашучы түбәндәге шартларның берсенә туры килергә

тиеш:

1) шәхси эшмәкәр, оештыру-хокукый формасына һәм милек формасына карамастан, закон белән билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затның гамәлгә куючысы (гамәлгә куюда катнашучысы) булып тора;

2) оештыру-хокукый формасына һәм милек формасына карамастан, Россия Федерациясе территориясендә закон белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән юридик затның башкарма органы составына керә;

3) үзмәшгуль булып тора.

7. Конкурста катнашуга түбәндәге компанияләрне тәкъдим итүче затлар кертелми:

1) Россия Федерациясе законнары белән тыелган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы;

2) алкогольле һәм спиртлы продукция, сыра һәм аның нигезендә җитештерелгән эчемлекләр, шулай ук тәмәке, тәмәке эшләнмәләре, тәмәке тарту кирәк-яраклары җитештерү яки сату буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы;

3) азартлы уеннар оештыручы һәм үткәрүче.

## 4 бүлек. Конкурсны үткәрү сроклары һәм тәртибе

8. Конкурс этаплап үткәрелә:

1) I этап – читтән торып. 2023 елның 15 сентябреннән 2023 елның 31 октябренә кадәр катнашучылар оештыру комитетына Chelnyanp@gmail.com электрон адреска заявка бирәләр, белешмәләр өчен телефон 8-951-068-00-77. Оештыру комитеты заявкаларны карап тикшерә һәм II этапта катнашучыларны билгели. Заявканы карап тикшергәндә оештыру комитеты тәкъдим ителгән материалларның тулылыгын тикшерә. Заявка бирү срокларын бозу конкурста катнашудан баш тарту өчен нигез булып тора;

2) II этап – урында. Конкурста катнашучылар тарафыннан бизнес проектларны жюри әгъзаларына ачык презентацияләү. 2023 елның 15 ноябреннән үткәрелә;

3) финал – җиңүчеләрне игълан итү һәм бүләкләү тантанасы. Көн оештыру комитеты тарафыннан II этап тәмамланганнан соң билгеләнә.

## 5. Конкурсның эчтәлеге

9. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

1) «Ел ачышы»;

2) «Уңышлы  старт»;

3) «Социаль эшмәкәрлек»;

4) «Иң яхшы бизнес идеясе»;

5) «Автокала эшмәкәре».

10. Конкурста катнашу өчен заявка үз эченә алырга тиеш:

1) әлеге нигезләмәгә 1 нче кушымта буенча катнашучының теркәү формасы;

2) әлеге нигезләмәгә 2 нче кушымта буенча теркәү формасына кушымта.

## 6 бүлек. Конкурста катнашучыларны бәяләү критерийлары һәм тәртибе

9. Барлык номинацияләрдә конкурста катнашучыларны бәяләү өчен гомуми критерийлар булып түбәндәгеләр тора:

1) эшмәкәрлек рухы – нәтиҗәле бизнес-идея булдыру, аны үстерү һәм тормышка ашыру, базар артыннан бару гына түгел, ә аның үзгәрү тенденцияләрен алдан күрү, стратегик һәм тактик максатлар кую һәм аларга ирешү сәләте;

2) идарә итү сәләте – бердәм һәм нәтиҗәле команда булдыру, хезмәткәрләрне үз идеяләрең белән мавыктыру һәм аларның потенциалын ачу сәләте;

3) инновацион якын килү – яңа товарлар һәм хезмәтләр эшләү һәм кертүдә иҗатка һәм новаторлыкка ориентлашу, компаниядә инновацияләр культурасын стимуллаштыру;

4) бизнесның социаль әһәмияте – яңа эш урыннары булдыру; хезмәткәрләрнең казанышларын хөрмәт итү, тану мохите булдыру, аларның компания тормышында актив катнашуларын бүләкләү; яшьләрне хезмәт эшчәнлеге процессына җәлеп итү, беренче чиратта кирәкле товарлар һәм хезмәтләр күрсәтү яки халыкның социаль якланмаган катламнарына ориентлаштыру;

5) финанс күрсәткечләре – бизнес үсешенең тотрыклылыгын күрсәтүче рентабельлек һәм үсеш күрсәткечләренең позитив динамикасы;

6) эшмәкәр шәхесенең тулылыгы – авырлыкларны җиңеп чыгу, куркынычларлар белән идарә итү, билгесезлек шартларында дөрес карарлар кабул итә белү, белем дәрәҗәсе һәм үзлегеннән үсү сәләте, хезмәткәрләр һәм конкурентлар тарафыннан хөрмәт һәм танылу.

12. Конкурста катнашучылар жюри әгъзалары тарафыннан түбәндәге бәяләү критерийлары нигезендә бәяләнә:

| № т/б | Критерий | Максималь бәя |
|---|---|---|
| 1. | Эшмәкәрлек рухы | 20 |
| 2. | Идарә итү сәләте | 10 |
| 3. | Инновацион якын килү | 20 |
| 4. | Бизнесның социаль әһәмияте | 20 |
| 5. | Финанс күрсәткечләре | 10 |
| 6. | Эшмәкәр шәхесенең тулылыгы | 20 |
| Максималь йомгаклау бәясе | | 100 |

## 7 бүлек. Конкурска йомгак ясау

13. Һәр номинациядә җиңүчеләр иң күп уртача баллга ия катнашучылар арасыннан жюри әгъзалары тарафыннан билгеләнә. Уртача балл тиешле заявкага жюри әгъзалары тарафыннан куелган баллар суммасын әлеге заявканы караучы жюри әгъзалары санына бүлеп исәпләп чыгарыла. Берничә претендентның уртача баллары тигез булган очракта, җиңүчеләрне сайлау жюри әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавышы нигезендә үткәрелә, тавышлар тигез булганда рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

14. Жюриның эш нәтиҗәләре беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

15. Жюриның эш нәтиҗәләре буенча конкурсның бер абсолют җиңүчесе һәм һәр номинациядә бер җиңүче билгеләнә. Җиңүчеләр дипломнар һәм түбәндәге күләмдә акчалата призлар белән бүләкләнә: конкурсның абсолют җиңүчесе – утыз мең сум; номинацияләрдә җиңүчеләр - унбиш мең сум.

16. Конкурс җиңүчеләренә эшмәкәрлек буенча региональ һәм бөтенроссия конкурсларында катнашырга тәкъдим ителә.

17. Конкурс җиңүчеләрен игълан итү һәм бүләкләү конкурс финалында тантаналы церемония барышында үткәрелә.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару
идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Г.А. Шәфыйкова

«Автокаланың яшь эшмәкәре – 2023»
конкурсы турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Катнашучының теркәлү формасы

| Конкурста катнашучы турында мәгълүматлар | |
|---|---|
| Фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| Номинация | ☐ «Ел ачышы»;<br>☐ «Уңышлы старт»;<br>☐ «Социаль эшмәкәрлек»<br>☐ «Автокала эшмәкәре»<br>☐ «Иң яхшы бизнес идеясе» |
| Туган көне | |
| Вазыйфасы, эш урыны | |
| Белеме (югары, урта һөнәри, уртагомуми) | |
| Гомуми эш стажы, тармакта, коллективта | |
| Соңгы 3 елда хезмәт эшчәнлеге / укуы:<br>Кергән / киткән ае һәм елы;<br>вазыйфасы / уку формасы;<br>оешма исеме һәм координатлары | |
| Өй адресы, телефоны, электрон почта адресы: | |
| Паспорт мәгълүматлары (сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелүе, подразделение коды, туган урыны) | |
| Оешма турында мәгълүматлар (әгәр кулланылса) | |
| Исеме | |
| Оештыру-хокукый формасы | |
| ИНН | |
| Төп эшчәнлек профиле, эшләп чыгарыла торган продукция / күрсәтелә торган хезмәт | |
| Адресы, предприятие индексы, телефоны, факсы, e-mail: | |

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм ______________________
Мин «Автокаланың яшь эшмәкәре – 2023» конкурсының шартлары белән килешәм

| ____________________ | ________________________ | ____________________________ |
|---|---|---|
| Датасы | Имзасы | Ф.И.А и. |

«Автокаланың яшь эшмәкәре – 2023»
конкурсы турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Номинацияләр өчен теркәлү формасы кушымтасының эчтәлеге

| № т/б | Исеме | Тәкъдим ителгән эчтәлеге |
|---|---|---|
| 1. | Катнашучы | Катнашучының эшмәкәрлек сыйфатларын, аның куркынычлар белән идарә итү осталыгын, билгесезлек шартларында карарлар кабул итү сәләтен, эш тәҗрибәсен, махсус күнекмәләрен, төп уңышларын һәм башкаларны тасвирлагыз. |
| 2. | Бизнесның үсеше | Катнашучының компаниясе тарихын тасвирлагыз. Компанияне төзү өчен өчен башлангыч идеяне һәм аның яңалык дәрәҗәсен, төзү процессының катлаулылык дәрәҗәсен / компанияне эшләтеп җибәрү һәм үстерү, булган финанс куркынычлары, катнашучы җиңгән башка мөһим каршылыкларны тасвирлагыз |
| 3. | Новаторлык алымы | Катнашучының төп продуктларны яки хезмәтләрне эшләү һәм кертү өчен иҗади һәм инновацион алымнарны ничек кулланганын тасвирлагыз. Катнашучы бизнесының уникаль үзенчәлекләрен, компания һәм аның конкурентлары арасындагы төп аермаларны тасвирлагыз. |
| 4. | Киләчәккә планнар | Катнашучының компаниянең киләчәге турында кыска сроклы һәм озын сроклы планлаштыру күнекмәләрен күрсәтә торган планнарын тасвирлагыз |
| 5. | Бизнес белән идарә итү | Катнашучының компания белән идарә итү өлкәсендәге казанышларына, стандарт булмаган һәм/яки нәтиҗәле идарә итү идеяләренә һәм компаниянең үсешенә ярдәм иткән карарларына конкрет мисаллар китерегез. Эш тәҗрибәсен, махсус күнекмәләрен һәм төп казанышларын күрсәтеп, компаниянең ике төп җитәкчесен (катнашучыдан тыш) тасвирлагыз |
| 6. | Социаль җаваплылык | Компаниядәге атмосфера хезмәткәрләрнең инициативасын күрсәтүгә, аларның һөнәри үсешенә һәм шәхси үсешенә ничек ярдәм итүен тасвирлагыз. Кушымтага катнашучының компаниядә социаль климатны яхшырту буенча инициативаларын тасвирлауны, компаниянең җирле һәм/яки региональ дәрәҗәдәге хәйрия акцияләрендә һәм социаль программаларда катнашу мисалларын кертегез. |

______________________ ______________________ ______________________
Дата Имзасы Ф.И.А и.